ГЛАВА КУРАЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КУРАЛОВО АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

11.10.2022 | с. Куралово | 02-02/3

Гражданнарның үзара салымын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Югары Ослан муниципаль районының Куралово авылы җирлегенең
Рус Бурнашы авылы гражданнар җыенын билгеләү турында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56нчы статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35нче статьясына, Югары Ослан муниципаль районы Куралово авыл җирлеге Уставының 24нче статьясына туры китереп,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2022 елның 25 октябрендә 11 сәгать 00 минутка Югары Ослан муниципаль районының Куралово авылы җирлегенең Рус Бурнашы авылы гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җыенның беренче этабын билгеләргә.

2. 2022 елның 25 октябрендә 13 сәгать 00 минутка Югары Ослан муниципаль районының Куралово авылы җирлегенең Рус Бурнашы авылы гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җыенның беренче этабын билгеләргә.

3. Халык исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.

1 этап: Рус Бурнашы авылы, Большая ур., Цветочная ур., Малая ур. халкы

2 этап: Рус Бурнашы авылы, Совет ур., Дальняя ур., Заречная ур. халкы

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«2022 елда Югары Ослан муниципаль районының Куралово авылы җирлегенең Рус Бурнашы авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 600 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме:

- товарны китерү белән тәэмин итүче хисабына билгеләнгән пунктка кадәр илтеп җиткерү белән Рус Бурнашы авылында юлларны ремонтлау өчен вак таш сатып алу, .

«ӘЙЕ» «ЮК».

5. Гражданнар җыеннарын үткәрергә:

1 этап: Рус Бурнашы авылының Зур урамы буенча 4-нче номерлы йорт янында

2 этап: Рус Бурнашы авылының Заречная урамы буенча 1-нче номерлы йорт янында.

6. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Куралово авыл җирлеге башлыгы Р.Е.Тарасов